КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 12 май г.Казань № б-941

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 23 декабрендәге б-3999 номерлы боерыгын гамәлгә ашыру максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 15 мартындагы б-615 номерлы боерыгы белән расланган 2036 елга кадәр Россия Федерациясендә гаилә һәм демография сәясәтен гамәлгә ашыру, күп балалыкка ярдәм күрсәтү гамәлләре стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын (алга таба – Чаралар планы) расларга.

2. Чаралар планын гамәлгә ашыру өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнарына:

Чаралар планы үтәлешен тәэмин итәргә;

ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 20 гыйнварына кадәр, Чаралар планының үтәлеше турындагы хисапны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына кертергә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Чаралар планында күрсәтелгән республика башкарма хакимият органнары тарафыннан тапшырыла торган мәгълүмат җыюны гамәлгә ашырырга һәм гомумиләштерелгән мәгълүматны ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына кертергә.

4. Чаралар планын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында әлеге максатлар өчен бюджет акчасы белән тиешле баш эш итүчеләргә каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин